ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2019 Казан шәһәре № 3-18/э

«Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020-2024 елларга аерым тарифлар билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

2. Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен, шушы карарның 2 нче

кушымтасына туры китереп, 2020-2024 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары билгеләргә.

3. Әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыятенең 2020-2024 еллар кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2019 № 3-18/э карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| № п/п | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте - «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 354 382,24 | 43,54 | 0,94640 | 354 382,24 | 43,54 | 0,94640 |
| | | 2021 | 355 712,45 | 44,85 | 0,95109 | 355 712,45 | 44,85 | 0,95109 |
| | | 2022 | 353 515,36 | 46,19 | 0,94684 | 353 515,36 | 46,19 | 0,94684 |
| | | 2023 | 351 410,76 | 47,58 | 0,94286 | 351 410,76 | 47,58 | 0,94286 |
| | | 2024 | 349 394,77 | 49,01 | 0,93915 | 349 394,77 | 49,01 | 0,93915 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2019 № 3-18/э карарына 2 нче кушымта

Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен 2020-2024 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Контрольдәге чыгымнарның база дәрәҗәсе | Контрольдә тотылырга тиешле чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Активлар саны буенча контрольдәге чыгымнарның сыгылмалылык коэффициенты | Электр челтәрләре аша тапшырганда электр энергиясен югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача дәвамлылыгы күрсәткече | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача ешлыгы күрсәткече | Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфат дәрәҗәсе күрсәткече |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | млн сум | % | % | % | сәгать | данә | |
| 1 | «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте | 2020 | 38,287 | 7 | 75 | 1,68 | 0,44900 | 0,24600 | 1,500 |
| | | 2021 | X | 7 | 75 | X | 0,44200 | 0,24300 | 1,477 |
| | | 2022 | X | 7 | 75 | X | 0,43600 | 0,23900 | 1,455 |
| | | 2023 | X | 7 | 75 | X | 0,42900 | 0,23600 | 1,434 |
| | | 2024 | X | 7 | 75 | X | 0,42300 | 0,23200 | 1,412 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2019 № 3-18/э карарына 3 нче кушымта

«Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыятенең (югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча) 2020-2024 елларга кирәкле тулай кереме

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте | 2020 | 292 875,66 |
| | | 2021 | 293 975,00 |
| | | 2022 | 292 159,23 |
| | | 2023 | 290 419,91 |
| | | 2024 | 288 753,82 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге